ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

_22.12.2021_ с. Муслюмово № _629_

**4 һәм аннан  күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турында нигезләмәне раслау хакында**

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулысынча туклану белән тәэмин итү, шулай ук укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар күрсәтү максатыннан Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. 4 һәм аннан  күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турындагы нигезләмәне яңа редакциядә расларга (1 нче кушымта).

2. Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының  «4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2021 ел, 22 март, 124 нче карары  (2021 ел, 29 июнь, 263 нче карары төзәтмәләре белән) үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый-мәгълүмати рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Мөслим муниципаль районы рәсми сайтында  бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары Бәдретдинова М. Р. йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **Хуҗин А.Р.**

Башкарма комитетның
2021 ел, “22” декабрь
№ 629 санлы
карарына кушымта

**4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфларында белем алучы 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган гаиләләргә адреслы, максатчан социаль ярдәм күрсәтү максатларында эшләнде һәм аларны бер тапкыр бушлай туклану белән тәэмин итү шартларын билгели.
1.2. Бер тапкыр бушлай бирелә торган туклану (төшке аш) белән тәэмин итү хокукы өчен:
* 4 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаилә балаларына гариза биргән көнгә 18 яшь тулмаган булуы шарт булып тора.
1.3. Гаиләсендә 4 һәм аннан да күбрәк баласы булган, урта гомуми белем бирү учреждениеләрендә (Мөслим гимназиясе, Мөслим лицее, Г.Тукай ис. Мөслим урта мәктәбе, Михайловка урта мәктәбе, Тат.Бүләр урта мәктәбе, Күбәк урта мәктәбе) белем алучы күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен иртәнге кайнар аш 19,20 (унтугыз сум 20 тиен) – ата-аналар түләве һәм 35 (утыз биш) сумлык төшке кайнар аш - 26,7 (егерме алты сум 70 тиен) сум Мөслим муниципаль районы бюджетыннан, 8,30 (сигез сум утыз тиен) сум субсидия исәбеннән «2022 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» 07.09.2021 ел, № 842 санлы карары нигезендә оештырыла.

Гаиләсендә 4 һәм аннан күбрәк баласы булган, төп гомуми белем бирү учреждениеләрендә (Мари-Бүләр, Тойгелде, Әмәкәй, Баек, Түбән Табын, Тат. Шуран, Яңа Усы, Рус.Шуган, Баланны, Салауз-Мухан, Олы Чакмак төп гомуми белем бирү мәктәбе) белем алучы күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен 35 (утыз биш) сумлык төшке кайнар аш - 26,7 (егерме алты сум 70 тиен) сум Мөслим муниципаль районы бюджетыннан, 8,30 (сигез сум утыз тиен) сум субсидия исәбеннән «2022 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында» 07.09.2021 ел, № 842 санлы карары нигезендә оештырыла.

## II. Түләүсез туклану бирү тәртибе

2.1. Гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе ата-аналарга күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү йөзеннән балаларга бер тапкыр бушлай туклану хокукы бирелүе турында хәбәр итә.
2.2. Ташламалы категориягә ия булган гаиләдә укучы баланың ата-анасы (законлы вәкиле) түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын алу өчен гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчесе исеменә түбәндәге документларны тапшыра:
- язмача гариза (нигезләмәнең 1 нче кушымтасы);

- күп балалы гаилә таныклыгы күчермәсе;
- барлык балаларның туу турында таныклыклары күчермәләре.

2.3. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары һәм тиешле документлар пакеты гомуми белем бирү учреждениесе администрациясе тарафыннан карала. Тапшырылган документлар нигезендә гомуми белем бирү учреждениесе директоры боерыгы рәсмиләштерелә.

2.4. Гомуми белем бирү учреждениесе бер тапкыр бушлай ашату бирелә торган барлык гаилә балаларының (туган даталары белән) санын алып бара.

2.5. Мөрәҗәгать итүчеләрнең гаризалары елга ике тапкыр карала: 30 сентябрьгә һәм 30 гыйнварга кадәр.

2.6. 30 сентябрьдән соң килгән гаризалар киләсе елның гыйнвар аенда, 30 гыйнвардан соң кергән гаризалар киләсе уку елының сентябрендә карала.

2.7. Учреждение укучыларның туклануын оештыру һәм аның сыйфаты өчен җаваплы.

2.8. Боерыкларның күчермәләре «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУсенә ел саен 30 сентябрьгә һәм 30 гыйнварга кадәр бирелә.

2.9. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ түләүсез туклану белән тәэмин ителүче укучыларның гомуми исемлеген формалаштыра.

2.10. Исемлеккә кертелгәннән соң, түләүсез туклану белән тәэмин итү хокукын бирүче документларның күчермәләре гариза бирүчегә кире кайтарыла.

2.11. Исемлек билгеләнгән тәртиптә эшләү өчен Үзәкләштерелгән бухгалтериягә тапшырыла.

2.12. Тапшырылган документларның дөреслеге өчен баласына бушлай туклану бирүне сорап гариза бирүче ата-аналар (законлы вәкилләр) җаваплы.

“4 һәм аннан  күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдәге балалар өчен түләүсез туклануны оештыру турында Нигезләмә”гә
1 нче кушымта

МББУ ___________________________________________
________________________________ директорына

________________________________________________
*(мөрәҗәгать итүченең Ф.И.О.)*
Адресы __________________________________________
________________________________________________
тел. ____________________________________________

гариза

Күп балалы гаилә әгъзасы булган  (Ф.И.О.)_______________________________________________ _______сыйныф  укучысына,  уку  көненә  бер  тапкыр  МББУ  ________________________________ ашханәсендә түләүсез туклану хокукын бирүегезне сорыйм.

Гаризага түбәндәге документларны терким:
- күп балалы гаилә таныклыгы күчермәсе;
- барлык балаларның туу турында таныклыкларының күчермәсе.

Имза:
Дата: